КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 ноябрь г.Казань № 925

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2013 ел, 18 апрель, 266 нчы карары белән расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен һәм алардан файдалану режимын раслау турында» 2013 ел, 18 апрель, 266 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 май, 340 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Казан шәһәрендә урнашкан төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территорияләреннән файдалану режимына, аңа түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 126 нчы йорт (Тукай урамы, 126 нчы йорт) адресы буенча урнашкан «Крестовников йорты, XIX гасыр» төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләрендә җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре: коммуналь хезмәт күрсәтү, эшмәкәрлек, складлар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\925.docx